# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Җәмгыяви иминлек фонды акчалары хисабыннан түләнгән дәвалану һәм ял итү юлламаларының хакыннан алынучы керем салымын түләүдән физик затларны азат итү турында

Татарстан Республикасы Югары Советы КАРАР БИРӘ:

1 статья. Физик затларның еллык гомуми кереме составына җәмгыяви иминлек фонды акчалары хисабыннан түләнгән дәвалану һәм ял итү юлламаларының хакы кертелми дип билгеләргә.

2 статья. Әлеге Законны басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1994 елның 20 апреле
N 2105-XII